**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

2023 елның 16 гыйнвары № 117

2023 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Олы Ачасыр авыл җирлеге» Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Ачасыр авыл җирлеге җирле үзидарә органнарында 2023 елда яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс үткәрелмәвен билгеләргә.
2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен Олы Ачасыр авыл җирлеге башлыгы урынбасарына йөкләргә.

**Олы Ачасыр авыл җирлеге**
**башлыгы урынбасары, Совет рәисе** **М.Г. Гатиятуллин**